ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.06.2026 п.г.т.Алексеевское № 229

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 02.07.2021 ел, № 257 «Инфраструктура үсеше бүлегенең муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатында, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан эшләрне башкару тәртибен раслау һәм тәкъдим итүнең административ регламентларын раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында»2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының «Инфраструктура үсеше бүлегенең муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2021 елның 02 июлендәге 257 номерлы карарына 1 нче кушымтаны яңа редакциядә (кушымта) бәян итәргә.
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтына http://alekseevskiy.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Е.Н.Мельниковка йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**Җитәкчесе** **О.Н. Леденцов**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының _10.06.2026
ел,__ № __229__карарына кушымта

**Капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерү турында карар бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламенты**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерү турында карар бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен билгели (алга таба – муниципаль хезмәт).

2. Хезмәтне алучылар: физик (шул исәптән шәхси эшмәкәрләр) һәм юридик затлар (алга таба - мөрәҗәгать итүче).

Мөрәҗәгать итүчеләр мәнфәгатьләрен мөрәҗәгать итүче тарафыннан билгеләнгән тәртиптә вәкаләтләр тапшырылган затлар һәм физик затларның законлы вәкилләре (алга таба – мөрәҗәгать итүче вәкиле) яклый ала.

3. Муниципаль хезмәт мөрәҗәгать итүчегә мөрәҗәгать итүченең категорияләре (билгеләре) нигезендә күрсәтелергә тиеш, алар «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталы» (алга таба – Бердәм портал) федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла.

## II. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

Муниципаль хезмәтнең атамасы

4. Капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерү турында карар бирү.

Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның исеме

5. Муниципаль хезмәтне Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба-Башкарма комитет) күрсәтә.

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе

6. Мөрәҗәгать итүче «Капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерүне» сорап мөрәҗәгать иткәндә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре булып тора:

1) капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерү турында карар (1 нче кушымта);

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буларак реестр язмасын формалаштыру каралмаган.

Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүче сайлау буенча муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризада күрсәтелгән ысул белән җибәрелә.

7. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә «Электрон имза
турында» 2011 елның 06 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 3-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә Башкарма комитет (яки Башкарма комитет) вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле имзасы куелган электрон документ рәвешендә Бердәм порталның, Республика порталының шәхси кабинетына җибәрелә.

8. Мөрәҗәгать итүченең теләге буенча, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе КФҮтә Башкарма комитет тарафыннан җибәрелгән, КФҮ мөһере һәм КФҮ хезмәткәре имзасы белән расланган кәгазьдә бастырылган электрон документ нөсхәсе рәвешендә алынырга мөмкин.

9. Мөрәҗәгать итүче хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ рәвешендә яисә электрон документның нөсхәсен кәгазь чыганакта хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең гамәлдә булу срогы дәвамында алырга хокуклы.

Муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты

10. Башкарма комитетка, КФҮтә, Бердәм портал, Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә мөрәҗәгать итүченең категориясенә (билгеләренә) бәйсез рәвештә, муниципаль хезмәт күрсәтүнең максималь срогы 10 эш көненнән артмый.

Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы гаризаны теркәгән көннән соң икенче көннән исәпләнә башлый.

11. Муниципаль хезмәт күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.

12. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документны электрон документ формасында җибәрү муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә башкарыла.

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең һәм муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

13. Гаризаны һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр, мөрәҗәгать итүченең категориясен (билгеләрен) исәпкә алып, регламентның 4 нче кушымтасында китерелгән.

14. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк.

15. Гаризаны һәм хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр, мөрәҗәгать итүченең категориясен (билгеләрен) исәпкә алып, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр регламентның 4 нче кушымтасында китерелгән.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

16. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен түләү алу Россия Федерациясе законнары белән каралмаган.

Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза белән мөрәҗәгать иткәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты

17. Муниципаль хезмәт алуга гариза биргәндә көтү вакыты - 15 минуттан артык түгел.

18. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

Мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы мөрәҗәгатен теркәү срогы

19. КФҮтә гариза биргән көнне КФҮкә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә мөрәҗәгать итүчегә гаризаның җибәрелүен раслаучы теркәү номеры белән гариза бирү датасын күрсәтеп, КФҮ АМСнан раслама бирелә.

20. Гаризаны Бердәм портал, Республика порталы аша җибәргәндә, мөрәҗәгать итүче гариза биргән көнне Республика порталының шәхси кабинетында һәм электрон почта аша гаризаның җибәрелгәнлеген раслый торган, теркәлү номерын һәм гариза биргән датаны күрсәтеп, хәбәрнамә ала.

21. Башкарма комитетка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, гариза бирү көнендә, Башкарма комитетның вәкаләтле вазифаи заты тарафыннан мөрәҗәгать итүчегә гаризаны кабул итү датасы һәм аңа кушылган документлар күрсәтелгән бер нөсхә кире кайтарыла.

Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр

22. Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә башкарыла.

Мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итү урыннары документлар тутыру өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырыла.

23. Инвалидларны социаль яклау турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү урынына каршылыксыз керү максатыннан түбәндәгеләр тәэмин ителә:

1)инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз

керү мөмкинлеге (бүлмәләргә уңайлы керү/чыгу һәм аларның эчендә хәрәкәт итү);

2) муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла;

3)күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясенең тотрыклы бозылуы булган инвалидларны озата бару һәм аларга ярдәм күрсәтү;

4)социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектлары урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге, мондый объектларга керү һәм чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшерү, шул исәптән кресло-колясканы файдаланып;

5)инвалидларның тормыш эшчәнлеге чикләүләрен исәпкә алып, хезмәт күрсәтүләргә тоткарлыксыз керүен тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат саклагычларын тиешенчә урнаштыру;

6)инвалидлар өчен кирәкле тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны Брайль рельефлы-нокталы шрифты белән башкарылган билгеләр белән кабатлау;

7)сурдотәрҗемәче һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;

8)озата баручы этне махсус өйрәтүне раслый торган һәм Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Озата баручы этне махсус өйрәтүне раслый торган документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386 номерлы боерыгы белән билгеләнгән форма буенча һәм тәртиптә бирелә торган документ булганда кертү.

24. Инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтелә торган объектлардан һәм муниципаль хезмәт күрсәткәндә кулланыла торган чаралардан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү буенча Регламентның 24 пунктының 1-4 пунктчаларында күрсәтелгән таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга кертелгән яки яңартылган, реконструкцияләнгән объектларга һәм чараларга карата кулланыла.

25. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга таләпләр турындагы мәгълүмат Башкарма комитетның, КФҮнең рәсми сайтында, шулай ук бердәм һәм Республика порталларында урнаштырыла.

## Муниципаль хезмәтнең һәркем файдалана алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре

26. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең үтемлелек күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документлар кабул итү һәм бирү башкарыла торган бүлмәнең җәмәгать транспорты йөри торган урында урнашкан булуы;

кирәкле белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган бүлмәләрнең җитәрлек санда булуы;

мәгълүмат стендларында, муниципаль районның рәсми сайтында, Бердәм порталда, Республика порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакытлары турында тулы мәгълүмат булу;

инвалидларга хезмәтләрдән башкалар белән тигез дәрәҗәдә файдаланырга комачаулый торган каршылыкларны узуда ярдәм итү.

27. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып тора:

1)документларны кабул итү һәм карап тикшерү вакытын үтәү;

2)муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алу вакытын үтәү;

3)Башкарма комитет хезмәткәрләре тарафыннан кылынган Регламентны бозуга карата нигезле шикаятьләр булмау;

4)мөрәҗәгать итүченең вазифаи затлар белән үзара аралашу саны (консультацияләрне исәпкә алмыйча):

4.1) мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәткәндә КФҮ хезмәткәрләре белән хезмәттәшлеге барлык кирәкле документлар белән гариза биргәндә бер тапкыр гамәлгә ашырыла;

4.2) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен кәгазьдә электрон документның нөсхәсе рәвешендә КФҮтә алу кирәк булган очракта, бер тапкыр.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән бер хезмәттәшлек дәвамлылыгы 15 минуттан артмый.

Мөрәҗәгать итүче кучмә радиотелефон элемтәсе җайланмалары ярдәмендә муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфатын Бердәм портал, Республика порталы, терминаль җайланмалар ярдәмендә бәяләргә хокуклы.

28.Хезмәт күрсәтүнең мөрәҗәгать итүчеләрнең ихтыяҗларына туры килүенә тикшерү кире элемтәне җыю турында билгеләнгән нигезләмәдә анализлау нигезендә даими үткәрелә.

Хезмәт күрсәтү процессларын оптимальләштерү мөрәҗәгать итүчеләрнең хезмәт күрсәтү процессыннан канәгатьлек дәрәҗәсе тотрыклы кимегән очракта (өч айдан артык рәттән) башкарыла.

Хезмәт күрсәтү процессы белән канәгатьлек дәрәҗәсе кимемәгән очракта, оптимальләштерү кимендә биш елга бер мәртәбә үткәрелә.

29. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы һәм статусы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Бердәм порталдагы шәхси кабинетта яисә республика Порталында, күп функцияле үзәктә алынырга мөмкин.

30. Муниципаль хезмәт күрсәтү мөрәҗәгать итүче сайлаган теләсә кайсы КФҮ тә аның яшәү урынына яисә фактта яшәү (булу) урынына бәйсез рәвештә экстерриториаль принцип буенча башкарыла.

31. Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәтне комплекслы гарызнамә составында алырга хокуклы.

32. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык һәм сыйфатлы күрсәткечләре турында мәгълүмат Башкарма комитетның, КФҮнең рәсми сайтында, шулай ук бердәм һәм республика порталларында урнаштырыла.

Муниципаль хезмәт күрсәтүгә башка таләпләр

33. Муниципаль хезмәт электрон рәвештә күрсәтелгәндә, мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләргә хокуклы:

а) Бердәм порталда, Республика порталында урнаштырылган муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм вакытлары турында мәгълүматтан файдаланырга;

б) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон образлары элегрәк 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешенең 7.2 пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны Бердәм порталдан, Республика порталыннан файдаланып тапшырырга;

в) электрон рәвештә бирелгән муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаларның үтәлеше барышы һәм статусы турында мәгълүмат алырга;

г) муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфатын Бердәм портал, Республика порталы ярдәмендә бәяләргә;

д) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ рәвешендә алырга;

е) Башкарма комитетның, шулай ук аның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) Бердәм портал, Республика порталы, федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы аша дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан башкарылган карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр шикаять бирү процессын тәэмин итә торган шикаять бирергә.

34. Гаризаны формалаштыру Бердәм порталда, Республика порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән, теләсә нинди башка формада гариза бирү зарурлыгыннан башка гамәлгә ашырыла.

35. Мөрәҗәгать итүчеләрне КФҮтә кабул итүгә язу (алга таба - язылу) Республика порталы, КФҮ контакт-үзәге телефоны аша гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчегә күпфункцияле үзәктә билгеләнгән кабул итү графигы буенча кабул итү өчен теләсә нинди буш көнгә һәм вакытка язылу мөмкинлеге бирелә.

Билгеле бер көнгә язылу әлеге көн башланырга бер тәүлек кала тәмамлана.

Республика порталы аша алдан язылу өчен мөрәҗәгать итүчегә система тарафыннан соратыла торган мәгълүматларны күрсәтү зарур, шул исәптән:

фамилиясен, исемен, атасының исемен (булган очракта);

телефон номерын;

электрон почта адресын (теләк буенча);

кабул итү буенча теләгән көнен һәм вакытын.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан алдан язылу вакытында хәбәр ителгән мәгълүматлар шәхси кабул итү вакытында мөрәҗәгать итүче тапшырган документларга туры килмәгән очракта, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Алдан язылып куйганда мөрәҗәгать итүчегә талон-раслауны бастырып чыгару мөмкинлеге тәэмин ителә. Мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын хәбәр иткән очракта, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат, кабул итү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, күрсәтелгән адреска җибәрелә.

Алдан язылуны гамәлгә ашырганда, мөрәҗәгать итүчегә, билгеләнгән кабул

итү вакытыннан соң 15 минут үткәннән соң килмәгән очракта, алдан язылу гамәлдән чыгарылуы турында мәҗбүри рәвештә хәбәр ителә.

Мөрәҗәгать итүче алдан язылу вакытыннан теләсә кайсы вакытта баш тартырга хокуклы.

Мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификация һәм аутентификация узудан тыш башка гамәлләр кылуны, кабул итүнең максатын күрсәтүне, шулай ук кабул итү өчен броньларга кирәк булган вакыт интервалы озынлыгын исәпләү өчен кирәкле белешмәләрне бирүне таләп итү тыела.

36. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри өстәмә хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

37. Мөрәҗәгать итүче һәм (яисә) мөрәҗәгать итүчегә караган объектлар һәм (яисә) башка объектлар турында белешмәләрне, шулай ук мөрәҗәгать итүченең белемнәрен (күнекмәләрен) аларның Россия Федерациясе законнары таләпләренә (дәүләт хезмәте күрсәтү (бирүдән баш тарту) турында Карар кабул итү процедурасы кысаларында тикшерелә торган таләпләрдән тыш), административ процедура таләпләренә туры килү-килмәвен бәяләү үткәрелә торган административ процедураны гамәлгә ашыру, дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар кабул ителгәннән соң гамәлгә ашырыла торган чикләнгән ресурсны (шул исәптән җир кишәрлекләрен, радиоешлыкларны, квоталарны), мөрәҗәгать итүчедән өстәмә белешмәләр алуның административ процедурасын, бер дәүләт хезмәте күрсәтү кысаларында ике һәм аннан да күбрәк мәртәбә кабатланырга рөхсәт ителә торган дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып торуның административ процедурасын күздә тоткан бүленеш каралмаган.

Муниципаль хезмәт күрсәтүгә кирәкле документларның
тулы исемлеге

38. Регламентка 3 нче кушымта таблицасында муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге китерелгән, анда түбәндәгеләр керә:

а) мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен тапшырырга тиешле документлар;

б) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль рәвештә тапшырырга хокуклы документлар.

39. Гаризаның һәм хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның рәвешләре турындагы белешмәләр әлеге Регламентның 3 нче кушымтасында китерелгән.

## III. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакыты

Административ процедуралар исемлеге

40. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза һәм документлар кабул итү;

2) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек;
3) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;
4) мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү.

## Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек

Хезмәт күрсәтүне алу өчен «Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша түбәндәге ведомствоара мәгълүмати гарызнамәләрне җибәрергә кирәк:

1) «Җир кишәрлегенә һәм (яисә) капиталь төзелеш объектына күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан исемлек» дигән мәгълүмат соратып алу. Күрсәтелгән мәгълүмати гарызнамә «Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәтенә» муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып 1 эш көне дәвамында җибәрелә. «Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәте» ведомствоара гарызнамә җибәрелгәннән соң соратылган белешмәләрне 2 эш көненнән артык булмаган вакытта бирә;

2) «Юридик затларның Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә» дигән мәгълүмати сорау. Күрсәтелгән мәгълүмати гарызнамә «Федераль салым хезмәте» нә муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып 1 эш көне дәвамында җибәрелә. «Федераль салым хезмәте» ведомствоара гарызнамә җибәрелгәннән соң, соралган белешмәләр 5 эш көненнән дә артык булмаган вакытта бирә. Юридик зат хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта сорау башкарыла;

3) «Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә» мәгълүмати соратып алу. Күрсәтелгән мәгълүмати гарызнамә «Федераль салым хезмәте» нә муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып 1 эш көне дәвамында җибәрелә. «Федераль салым хезмәте» ведомствоара гарызнамә җибәрелгәннән соң, соралган белешмәләр 5 эш көненнән дә артык булмаган вакытта бирә. Шәхси эшмәкәр хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта сорау башкарыла.

42. Муниципаль хезмәтләр алу өчен түбәндәге ведомствоара мәгълүмати гарызнамәләрне башка сервислар ярдәмендә җибәрергә кирәк:

1) «Мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиле вәкаләтләрен раслый торган документ» дигән мәгълүмати гарызнамә. Күрсәтелгән мәгълүмати гарызнамә, хезмәт күрсәтүне мөрәҗәгать итүче вәкиле сорап мөрәҗәгать иткән очракта, «Граждан хәле актларын теркәү Бердәм дәүләт реестры» сервисы яки «Социаль тәэмин итүнең Бердәм дәүләт мәгълүмат системасы» сервисы ярдәмендә 1 эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла;

2) «Ышанычнамәне бирү факты һәм аның эчтәлеге турында белешмәләр» дигән мәгълүмати гарызнамә. Күрсәтелгән мәгълүмати гарызнамә, мөрәҗәгать итүче вәкиле хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта, «Нотариатның Бердәм мәгълүмат системасы» сервисы ярдәмендә 1 эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

3) «Мәдәни мирас объектларын саклау зоналары чикләрендә игълан ителгән параметрлары белән капиталь төзелеш объектын урнаштыру яисә реконструкцияләү мөмкинлеге турында» Күрсәтелгән мәгълүмати гарызнамә Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты (федераль, региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары өлешендә) йә башкарма комитетының структур бүлекчәсе (җирле әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары өлешендә) тарафыннан 5 эш көненнән дә артык булмаган вакытта соратып алына;

4) «Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы» дигән мәгълүмат гарызнамәсе. Күрсәтелгән мәгълүмати гарызнамә Башкарма комитетның структур бүлекчәсеннән 5 эш көненнән дә артык булмаган вакытта соратып алына;

5) «Территорияне планлаштыру документлары» дигән мәгълүмат гарызнамәсе. Күрсәтелгән мәгълүмати гарызнамә Башкарма комитетның структур бүлекчәсеннән 5 эш көненнән дә артык булмаган вакытта соратып алына;

6)«Капиталь төзелеш объектының архитектур-шәһәр төзелешен килештерү турында элек кабул ителгән карар (элек килештерелгән архитектура-шәһәр төзелешенең тышкы кыяфәте параметрлары үзгәргән очракта)» дигән мәгълүмат гарызнамәсе. Күрсәтелгән мәгълүмати гарызнамә Башкарма комитетының структур бүлекчәсеннән 5 эш көненнән дә артык булмаган вакытта соратып алына.

## IV. Мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гарызнамәне карау статусын үзгәртү турында хәбәр итү ысуллары

43. Техник мөмкинлек булганда, гариза бирүче Регламент белән билгеләнгән хезмәтне күрсәтү соравының статусын үзгәртү турында (хезмәтне күрсәтү өчен документлар кабул итү турында; гариза һәм документлар җыелмасын карау турында; хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү турында), шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге этабында мөрәҗәгать итүче башкарырга тиешле алдагы адымнар һәм гамәлләр турында, күрсәтелгән ысулларның берсе белән хәбәр ителә:

-смс-мәгълүмат бирү юлы белән;

-Бердәм портал ярдәмендә;

-Республика порталы ярдәмендә;

-башка сервислар һәм ысуллар ярдәмендә (булган очракта).

1 нче кушымта

# ШАРТЛЫ БИЛГЕЛӘР ҺӘМ КЫСКАРТУЛАР ИСЕМЛЕГЕ

1. Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (https://uslugi.tatarstan.ru/) - Республика порталы;
2. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы (https:/ www.gosuslugi.ru/) - Бердәм портал;
3. Реестр «Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең федераль реестры» (http://frgu3.gosuslugi.ru) федераль дәүләт мәгълүмат системасы;
4. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты -Башкарма комитет;
5. «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе - КФҮ.

2 нче кушымта

**Мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләр (билгеләр) идентификаторлары**

| | Хезмәтне күрсәтү нәтиҗәсе | Мөрәҗәгать итүченең аерым билгесе исеме | Гариза бирүчеләрнең аерым билгесе идентификаторы |
|---|---|---|---|
| 1. | Капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерү | Физик зат | 1А |
| 2. | | Юридик зат | 2А |
| 3. | | Шәхси эшмәкәр | 3А |
| 4. | | Мөрәҗәгать итүченең вәкиле | 4А |

3 нче кушымта

**Хезмәт күрсәтүгә кирәкле документларның тулы исемлеге**

| № | Идентификатор | Мөрәҗәгать итүче тапшыра торган документларның төрләрен ачыклау, бу төркемдәге документлар саны | Бирү ысулы |
|---|---|---|---|
| *Мөрәҗәгать итүче Хезмәт күрсәтү өчен мөстәкыйль рәвештә тапшырырга тиешле документлар* | | | |
| 1. | 1А-4А | Гариза | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |
| 2. | 1А-4А | Шәхесне таныклый торган документ | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |
| 3. | 4А | Мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ | Башкарма комитет, КФҮ |
| 4. | 1А-4А | Капиталь төзелеш объектының проект документациясе бүлекләре*:<br>а) аңлатма язуы;<br>б) җир кишәрлеген планлаштыру оештыру схемасы;<br>в) күләм-планлаштыру һәм архитектура чишелешләре. | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |
| *Мөрәҗәгать итүче хезмәт күрсәтү өчен үзе тапшырырга хокуклы документлар* | | | |
| 1. | 1А-4А | Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрында хокуклары теркәлмәгән капиталь төзелеш объектына, җир кишәрлегенә хокук билгеләүче документлар | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |

** Проект документациясе бүлекләренең текст һәм график өлешенең эчтәлеге Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 16.02.2008 ел, № 87«Проект документациясе бүлекләренең составы һәм аларның эчтәлегенә таләпләр турында» карарына туры килергә тиеш.*

*Проект документациясенең дәүләт серенә кагылышлы белешмәләр булган бүлекләре Россия Федерациясенең дәүләт сере турындагы законнары таләпләрен үтәгән килеш тапшырыла.*

4 нче кушымта

**Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен тулы нигезләр**

| № | Идентификатор | Мөрәҗәгать итүче тапшыра торган документларның төрләрен ачыклау, бу төркемдәге документлар саны |
|---|---|---|
| *Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр* | | |
| 1. | 1А-4А | Капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше йөзен билгели торган һәм проект документациясендәге йә төзүченең яисә капиталь төзелеш объектын проектлауга техник заказчының заданиесендәге архитектура карарларының капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше йөзенә шәһәр төзелеше регламентында күрсәтелгән, билгеләнгән таләпләргә туры килмәве_____________________________________________ _______ (шәһәр төзелеше регламентын раслый торган норматив хокукый актның реквизитларын күрсәтергә):<br>1) капиталь төзелеш объектының күләм-пространство характеристикаларына таләпләр;<br>2) капиталь төзелеш объектының архитектура-стилистик характеристикаларына таләпләр;<br>3) капиталь төзелеш объектларының төсле чишелешләренә таләпләр;<br>4) бизәү һәм (яисә) төзелеш материалларына капиталь төзелеш объектларының архитектура йөзен билгели торган таләпләр;<br>5) капиталь төзелеш объектлары фасадларында һәм түбәләрендә техник һәм инженерлык җиһазларын урнаштыруга таләпләр;<br>6) капиталь төзелеш объектлары фасадларын яктыртуга таләпләр». |
| 2. | 1А-4А | Мөрәҗәгать итүче инициативасы буенча муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны чакыртып алу |
| *Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр* | | |
| 1. | 1А-4А | Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тәкъдим ителгән документларда Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган текстны чистартулар һәм төзәтүләр бар |

| | | |
|---|---|---|
| 2. | 1А-4А | Документларда муниципаль хезмәт күрсәтү өчен документлардагы мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмдә файдаланырга мөмкинлек бирми торган зарарланулар бар |
| 3. | 1А-4А | Бирелгән документлар яисә белешмәләр муниципаль хезмәт өчен мөрәҗәгать итү вакытына үз көчләрен югалтты (шәхесне таныклый торган документ белешмәләре; мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ, күрсәтелгән зат тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта) |
| 4. | 1А-4А | Билгеләнгән таләпләрне бозып электрон рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар һәм муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гарызнамәне бирү |
| 5. | 1А-4А | Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле тулы булмаган документлар комплектын тапшыру |
| 6. | 1А-4А | Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза дәүләт хакимияте органына, җирле үзидарә органына яисә вәкаләтләренә муниципаль хезмәт күрсәтү кермәгән оешмага тапшырылган |
| 7. | 1А-4А | «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясында билгеләнгән чынбарлыкны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза дип тану шартларын үтәмәү |
| 8. | 1А-4А | Мөрәҗәгать итүче категориясенең хезмәт күрсәтү хокукына ия затлар даирәсенә туры килмәве |

5 нче кушымта

(Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган бланкы)

Капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр
төзелешенең тышкы йөзен килештерү турында
КАРАР
____________ № ______________

Муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризаны карау нәтиҗәләре буенча капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелешенең тышкы күренешен килештерү турында карар бирү __________________ № ____________, __________ архитектура-шәһәр төзелешенең тышкы күренешен килештерү турында карар кабул ителде ________, үткәргәндә ______________ адресы: ____________________.

Капиталь төзелеш объектының кадастр номеры: _________________, кадастр номерлы җир кишәрлегендә (кишәрлекләрендә) урнашкан һәм түбәндәге төп параметрлары булган капиталь төзелеш объекты:

- ________________________;
- ________________________;
- ________________________;

Кушымта: капиталь төзелеш объектының (объектлар төркемнәренең) архитектура-шәһәр төзелеше тасвирламасы буенча материаллар.

| Электрон имза турында белешмәләр |
|---|

Район Башкарма комитеты Җитәкчесе

____________________

6 нчы кушымта

(Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган бланкы)

Капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелешенең тышкы
йөзен килештерү турында карар бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүдән
баш тарту турында
КАРАР

_____________ (карар көне)

_____________ (карар номеры)

«Капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерү турында к арар бирү» муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны карау нәтиҗәләре буенча ________ № _____________ һәм аңа кушып бирелгән документлар нигезендә __________________________ (муниципаль хезмәт күрсәтүне җайга сала торган актның пункты, номеры, датасы һәм исеме күрсәтелә) адресы буенча урнашкан капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерүдән баш тарту турында карар кабул ителде:______________________________

________________________________________________________________________. Капиталь төзелеш объектының кадастр номеры (булган очракта)
__________________________________________, кадастр номеры булган җир кишәрлегендә урнашкан ___________________________________________,
функциональ билгеләнеше______________________________________________
________________________________________________________________________,
һәм(алар) түбәндәге төп параметрлары булган (мәйданы, катлылыгы):
________________________________________________________________________;
________________________________________________________________________.

Капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерүдән баш тарту өчен нигез булып тора: _________________________________________________
__________________________________________________________________________________.

Проект документациясе бүлекләрен эшләп бетерү буенча тәкъдимнәр (булганда)
__________________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________________.

Күрсәтелгән бозулар бетерелгәннән соң, муниципаль хезмәт күрсәтүгә вәкаләтле органга муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза белән кабат мөрәҗәгать итәргә хокуклы.
Мондый баш тартуга карата шикаятьне муниципаль хезмәт күрсәтүгә вәкаләтле органга җибәрү юлы белән судка кадәрге тәртиптә, шулай ук суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.

| Электрон имза турында белешмәләр |
|---|

Вазыйфаи зат (ФИА) _________________________________

(кул куюны гамәлгә ашыручы органның вазыйфаи заты имзасы)

Башкаручы (ФИА)

_____________________________
(башкаручы контакты )

7 нче кушымта

Юридик затлар өчен

(жирле үзидарә органы исеме)

______________________________________

______________________________________
(оешманың тулы исеме һәм
оештыру-хокукый формасы)
:

______________________________________

______________________________________
(Җитәкченең яисә башка
вәкаләтле зат ФИА)

Мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклаучы документ:

______________________________________
( документ төре)

______________________________________
(сериясе, номеры)

______________________________________
(кем кайчан биргән)

Юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр:

ОГРН

______________________________________

______________________________________

ИНН

______________________________________

Булу урыны

______________________________________

______________________________________

Контактлар:

номер тел. 1 ______________________

номер тел. 2 ______________________

эл. почта ______________________

Физик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр өчен

ФИА

______________________________________

Шәхесен таныклаучы документ:

______________________________________
(документ төре)

______________________________________
(сериясе, номеры)

(кем, кайчан биргән)

ОРГНИП (ИП өчен)

Теркәлү адресы

Ышанычнамә буенча вәкил яки законлы вәкил:
ФИА

Шәхесен таныклаучы документ:

(документ төре)

(сериясе, номеры)

(кем, кайчан биргән)

Вәкаләтләрне раслый торган документның реквизитлары:

Теркәлү адресы

Контактлар:
номер тел. 1 ____________________
номер тел. 2 ____________________
эл. почта ____________________

## ГАРИЗА ФОРМАСЫ

Объектның архитектур-шәһәр төзелешенең тышкы йөзен тәкъдим ителгән материаллар нигезендә килештерүегезне сорыйм.

Кирәкле мәгълүматлар исемлеге:

| | |
|---|---|
| Эш төрләре | |
| Җир кишәрлегенең кадастр номеры | |
| Капиталь төзелеш объектының кадастр номеры | |
| Объект исеме | |
| Архитектура проекты авторының ФИА (булган очракта) | |
| Территорияне планлаштыру документациясен раслау турында карар датасы (булган очракта) | |
| Территорияне планлаштыру документациясен раслау турындагы карар номеры (булган очракта) | |
| Территорияне планлаштыру документациясен раслаган органның исеме (булган очракта) | |

| | |
|---|---|
| Архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерү турында элек бирелгән карарның датасы (булган очракта) | |
| Архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерү турында элек бирелгән карарның номеры (булган очракта) | |
| Архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерү турында элек карар биргән органның исеме (булган очракта) | |
| Шундый ук күпфатирлы торак йортның архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерү турында карар датасы (булган очракта) | |
| Шундый ук күпфатирлы торак йортның архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерү турында карар номеры (булган очракта) | |
| Шундый ук күпфатирлы торак йортның архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерү турында карар биргән орган исеме (булган очракта) | |
| Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен минем адреска түбәндәге юл белән бирүегезне (җибәрүегезне) сорыйм: | |
| ☐ Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы, дәүләт хезмәтләре порталының шәхси кабинетына электрон рәвештә<br>☐ Электрон рәвештә Бердәм дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталының шәхси кабинетына<br>☐ Башкарма комитетта<br>☐ КФҮ тә | |

Гариза
имзасы бирүченең

__________________________
( имза расшифровкасы)

Дата ________________________________________

8 нче кушымта

(Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган бланкы)

### Капиталь төзелеш объектының архитектур-шәһәр төзелешенең йөзен килештерү турында карар бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар

Мөрәҗәгатенә бәйле рәвештә_______________________________________________
(Физик зат Ф.И.А., мөрәҗәгать итүче юридик затның атамасы )

_________________________________________________________________________

гариза №________ _______ ел__________________________________ турында

_________________________________________________________________________

_________________________________________________________________________

нигезендә:
тапшырылган документларны карау нәтиҗәләре буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителде:

1.

2.

Вазыйфаи зат (ФИА) ______________________________

(кул куюны гамәлгә ашыручы органның вазыйфаи заты имзасы)

| Электрон имза турында белешмәләр |
|---|

Башкаручы (ФИА)

____________________________

(башкаручы контакты)